| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2024 Буа шәһәре № 382 Бк/к

2025 елда Буа шәһәре һәм Буа муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру турында

Буа муниципаль районы укучыларын тулы һәм балансклы кайнар ризык белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 12 сентябрендәге 777 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны кайнар туклануның уртача хакын раслау турында» карары, ТР Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 20.10.2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы карары нигезендә, РФ Президентының «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы белән Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр билгеләргә:

1.1. Буа муниципаль районында гомуми башлангыч белем алучы укучыларны тукландыру бәясе 69 сум 43 тиен.

1.2.Шәһәр гомуми белем бирү оешмалары һәм авыл гомуми белем бирү оешмалары «ТР Буа муниципаль районы Кыят урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ, «ТР Буа муниципаль районы Әлши урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ,«ТР Буа муниципаль районы Протопопово урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ, «ТР Буа муниципаль районы Н.Г.Фәизов исемендәге Яңа Тинчәле төп

белем мәктәбе» МБГББУ, «ТР Буа муниципаль районы Ырынгы урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Ташкичү төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ укучыларына көнгә туклану бәясе 69 сум 43 тиен күләмендә, шул исәптән:

- уку чорында бер укучыга көнгә 9 сум 60 тиен күләмендә субсидия,
- уку чорында бер укучыга ата-аналар кертемнәре 59 сум 83 тиен.

1.3. «ТР Буа муниципаль районы Советлар Союзы Герое Шафранов Петр Григорий улы исемендәге Зур Фролово төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ авыл гомуми белем бирү оешмасында укучыларга туклану бәясе көнгә 73 сум 00 тиен күләмендә, шул исәптән:

- уку чорында бер укучыга көнгә 9 сум 60 тиен күләмендә субсидия,
- уку чорында бер укучыга көненә 63 сум 40 тиен күләмендә ата-ана кертемнәре.

1.4. Төп гомуми һәм урта гомуми белем алучы авыл гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны көнгә туклandыру бәясе 50 сумнан артмый, шул исәптән:

- уку чорында бер укучыга көнгә 9 сум 60 тиен күләмендә субсидия,
- уку чорында бер укучыга ата-аналар кертемнәре көненә 40 сум 40 тиеннән дә артмый.

1.5. Шәһәр гомуми белем бирү оешмалары һәм авыл гомуми белем бирү оешмаларында «ТР Буа муниципаль районы Кыят урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ, «ТР Буа муниципаль районы Әлши урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ, «ТР Буа муниципаль районы Протопопово урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ, «ТР Буа муниципаль районы Н.Г.Фәизов исемендәге Яңа Тинчәле төп белем мәктәбе» МБГББУ, «ТР Буа муниципаль районы Ырынгы урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Ташкичү төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ, «ТР Буа муниципаль районы Советлар Союзы Герое Шафранов Петр Григорий улы исемендәге Зур Фролово төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ төп гомуми һәм урта гомуми белем алучылар өчен ташламалы туклану бәясе 59 сум 83 тиен.

1.6. Төп гомуми һәм урта гомуми белем алучы авыл гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен ташламалы туклану бәясе 40 сум 40 тиен.

1.7. «ТР Буа шәһәренең лицей-интернаты (сәләтле балалар өчен мәктәп)» МБГББУ укучылары, «ТР Буа ш. лицей-интернаты (сәләтле балалар өчен мәктәп)» МБГББУ каршындагы интернатта яшәүчеләр, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем алучылар өчен биш тапкыр туклану бәясе ата-аналар түләвен һәм субсидияләрне исәпкә алып, җирле бюджет хисабына көнгә 290 сум 20 тиен күләмендә..

2. Буа муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны туклandыруны оештыру тәртибе турында нигезләмәне расларга (карарга кушымта).

3. 2025 елга гомуми белем бирү оешмаларының расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гаиләләргә адреслы һәм социаль ярдәм күрсәтү максатларында Буа шәһәре һәм Буа муниципаль районы гомуми белем бирү

оешмалары җитәкчеләренә түбәндәге категориядәге гаиләләрне ата-ана кертемнәрен түләүдән азат итәргә:

-3 һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләр (өч баланың олысына 18 яшь яисә 23 яшь тулганчы, әгәр бала көндезгедә укыса);

- инвалид балалары булган гаиләләр;

- сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалары булган, ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин ителә торган гаиләләр;

- ата-аналары сәламәтлеге буенча 1 һәм 2 төркем инвалид булган гаиләләр (эшләмәүче гражданнар);

- ата-аналары Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә үтәүче гражданнар, гаиләдәге балалар,махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре гаиләләрендәге балалар, шулай ук озайтылган көндә йөрүче балалалар гаиләләре;

- югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның ата-аналары махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гаиләләр (гаилә әгъзаларына) ;

- Донецк Халык Республикасыннан, Луганск Халык Республикасыннан килгән балалы гаиләләр.

4. Өйдә индивидуаль белем алучы, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларга ай саен медицина бәяләмәсе, акча нормативлары һәм азык-төлек җыелмасын акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеге нигезендә азык-төлек җыелмасын бирергә.

5. «ТР Буа муниципаль районының Финанс – бюджет палатасы» МКУ рәисенә (Р.Р. Әюповка) тиешле финанс елына Буа муниципаль районы мәгариф идарәсенең бюджет язмасында күрсәтелгән максатларга каралган акчаларны вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чаралары күрсәтүче органнар социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт системасын (алга таба - ЕГИССО) Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм ЕГИССО операторы билгеләгән тәртиптә һәм күләмнәрдә куллану юлы белән күрсәтелгән чаралар турында мәгълүмат җиткерүне тәэмин итәләр.

7. Әлеге карар имза салынган көннән законлы көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http//buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш һәм 2025 елның «01» гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

8. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елда Буа шәһәре һәм Буа муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2023 елның 12 декабрендәге 319/Бк/к номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л. Н.Садретдиновага йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов

Кушымта

Буа муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны тукландыруны оештыру тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныфларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ түбәндәге укучылар өчен түләүсез кайнар туклану рәвешендә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибен билгели:

-3 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдән (өч баланың олысына 18 яшь яисә 23 яшь тулганчы, әгәр бала көндезгедә укыса);

- сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар;

- инвалид балалар;

- ата-аналары 1 һәм 2 төркем сәламәтлек инвалидлары булган гаиләләрдән (эшләмәүче гражданнар);

- ата-аналары Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә үтәүче гражданнар, гаиләдәге балалар,махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре гаиләләрендәге балалар, шулай ук озайтылган көндә йөрүче балалалар гаиләләре;

- югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның ата-аналары махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гаиләләрдән (гаилә әгъзаларыннан) ;

- Донецк Халык Республикасыннан, Луганск Халык Республикасыннан балалы гаиләләрдән.

2. Укучыларны тукландыруны оештыру.

2.1. Гомуми белем бирү оешмаларында туклану буенча комиссия төзү.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү буенча комиссияләр (алга таба - комиссия) төзелә. Комиссия составы директор тарафыннан раслана. Комиссия составына укучыларны оештыру өчен җаваплы педагогны, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен, укучыларның ата-аналарын кертү тәкъдим ителә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны кимендә биш кеше булырга тиеш.

Комиссия:

- кушымтада каралган форма буенча укучы ата-аналардан социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында гаризалар кабул итә;

- өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучылар исемлеген 13.01.2025 елга кадәр раслый һ. б.

2.2. Сыйныф җитәкчеләре:

- ата-аналардан яисә аларны биләүче затлардан әлеге Нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча түләүсез туклануга гаризалар кабул итәләр;

- гаризаларны комиссия каравына алганнан соң өч көн эчендә җибәрәләр;

- сыйныфта укучыларның туклануын категорияләр буенча исәпкә алалар;

- укучылар һәм ата-аналар (законлы вәкилләр) арасында укучыларны тулы канлы тукландыру кирәклеге турында аңлату эшләре алып баралар;

- барлык сыйныф укучыларының ашханәгә йөрүләрен тикшереп торалар.

2.3. Ата-аналар (законлы вәкилләр) тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

2.4. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре:

- тапшырылган документлар нигезендә укучыларны категорияләр буенча түләүсез туклану белән тәэмин итүгә боерыклар чыгаралар;

- Буа муниципаль районы мәгариф идарәсенә категорияләрен күрсәтеп, ташламалы туклану буенча мәгълүмат тапшыралар;

- белем бирү оешмасы балансллы туклануны оештыру, азык-төлек блокларының торышы өчен санитария нормалары нигезендә җаваплы.

2.5. Укучыларны тукландыруны оештыру, азык әзерләү технологияләрен, санитария нормаларын үтәү мәсьәләләре белән Буа муниципаль районы мәгариф Идарәсе шөгыльләнә.

2.6. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин ителә.

2.7. Өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ һәм медицина бәяләмәсе нигезендә өйдә белем алучыларга ай саен билгеләнгән акча нормативлары һәм продукт җыелмасын акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеге нигезендә Азык-төлек җыелмасы бирелә.

Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының барлык гомуми белем бирү оешмаларына кагыла.

кушымта

«______________________________
______________________________
______________________________» МББУ укучыларының туклануын оештыру комиссиясенә

______________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А.и.)

______________________________
(адрес)

______________________________
______________________________

Гариза

Минем улым (кызым, тәрбиядәге)

_________________________________________________________________
(Ф.И.А.и..)

_________________________________________________________________
____________укучысы өчен бушлай туклану бирүегезне сорыйм.

Гаилә әгъзасының җан башына уртача кереме________________ сум.
Өстәмә рәвештә хәбәр итәм: ___________________________________________
_________________________________________________________________
Ташламаны раслаучы документларны кушымтада бирәм.

_________________________
(дата, имза)

Гаризага кушымта итеп бирелә:
1) күпбалалы гаилә турында таныклык күчермәсе;
2) балаларның туу турында таныклыклары;
3) опека һәм попечительлек бүлегеннән белешмә йә 3 һәм аннан күбрәк баласы булган балигъ булмаганнарга опека билгеләү турында күрсәтмә күчермәсе (өч баланың олысына 18 яшь яисә 23 яшь тулганчы, әгәр бала көндезгедә укыса);
4) инвалид балалар, инвалид ата – аналар өчен МСЭ медицина белешмәсе, Психология-медицина-педагогика комиссиясе белешмәсе күчермәсе.
5) махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән хәрби хезмәткәрләрнең ата-аналары өчен хәрби комиссариаттан белешмә.

кушымта

| № т/б | Белем бирү оешмасы исеме | Озайтылган көнендә 1 балага туклану бәясе | көненә 1 балага туклану бәясе 1-4 сыйныф | көненә 1 балага туклану бәясе 5-11 сыйныф |
|---|---|---|---|---|
| 1. | «ТР Буа шәһәре «1 нче номерлы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | 32 | 69,43 | 69,43 |
| 2. | ТР Буа муниципаль районы Буа шәһәренең «2нче Лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 23 | 69,43 | 69,43 |
| 3. | «ТР Буа шәһәре 5 нче гимназия» МБГББУ | 32 | 69,43 | 69,43 |
| 4. | «Татарстан Республикасы Буа шәһәре лицейинтернаты (сәләтле балалар мәктәбе)» МБГББУ | - | 69,43 | 69,43 |
| 5. | ТР Буа муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «Академик Р. З. Сәгъдиев исемендәге гомуми белем бирү мәктәбе» | 23 | 69,43 | 69,43 |
| 6. | «Татарстан Республикасы Буа шәһәре М.М. Вахитов исемендәге гимназия» МБГББУ | 32 | 69,43 | 69,43 |
| 7. | «ТР Буа муниципаль районы Адав-Толымбай урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | 9,6 | 69,43 | 50 |
| 8. | «ТР Буа муниципаль районы Аксу урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 9. | «ТР Буа муниципаль районы Әлши урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 69,43 |
| 10. | «ТР Буа муниципаль районы Алших урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69.43 | 50 |
| 11. | «ТР Буа муниципаль районы Боерган урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 12. | «ТР Буа муниципаль районы Кыят урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 69,43 |
| 13. | «ТР Буа муниципаль районы Протопопово урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 69,43 |
| 14. | «ТР Буа муниципаль районы Иске Суыксу урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 15. | « ТР Буа муниципаль районы Килдураз урта мәктәбе» МБГББУ. | - | 69,43 | 50 |
| 16. | «ТР Буа муниципаль районы Н.Г.Фәизов исемендәге Яңа Тинчәле төп белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 69,43 |
| 17. | «ТР Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 18. | «ТР Буа муниципаль районы Ырынгы урта гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 69,43 |
| 19. | «ТР Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге төп гомуми белем мәктәбе» | - | 69,43 | 50 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | МБГББУ | | | |
| 20. | ТР Буа муниципаль районы Янтуган авылы төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 21. | «ТР Буа муниципаль районы Бик-Үти төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 22. | «ТР Буа муниципаль районы Советлар Союзы Герое Шафранов Петр Григорий улы исемендәге Зур Фролово төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | 23 | 69,43 | 73 |
| 23. | «ТР Буа муниципаль районы Югары Лашчы төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69.43 | 50 |
| 24. | «ТР Буа муниципаль районы Ташкичү төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 69,43 |
| 25. | «ТР Буа муниципаль районы Ташкичү төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 26. | «ТР Буа муниципаль районы Күшке төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 27. | «ТР Буа муниципаль районы Карлы төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 28. | «ТР Буа муниципаль районы Түбән Нартабаш төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 29. | «ТР Буа муниципаль районы Кырык Садак төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 30. | «ТР Буа муниципаль районы Иске Тинчәле төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |
| 31. | «ТР Буа муниципаль районы Күл Черкене төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ | - | 69,43 | 50 |